| Килешенде: | Татарстан | Раслыйм: |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Мәгариф идарәсе башлыгы | Язучылары берлеге урынбасары Язучыларның Чаллы бүлеге җитәкчесе | Муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе "21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе" директоры |
| Н.В.Кашапов | Ф.М.Сафин | Р.Р.Калимуллин |

Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатына багышланган
IV төбәкара фәнни-гамәли конференция
нигезләмәсе.

I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Нигезләмә Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатына багышланган IV төбәкара фәнни-гамәли конференция (алга таба - Конференция) үткәрү максатын, бурычларын, тәртибен билгели. Конференцияне үткәрү тәртибе, алымнары үзгәрергә мөмкин.

1.2. Конференциядә гомуми белем бирү оешмаларының 3-11 сыйныф укучылары, гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре катнаша ала.

II. Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Укытучыларны һәм укучыларны, фәнни-эзләнү эшләренә тарту, интеллектуаль сәләтләрен һәм иҗади фикерләвен активлаштыру.

2.2. Бурычлары:

- Яр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче, шулай ук Яр Чаллы шәһәреннән чыккан хәзерге вакытта башка шәһәрләрдә яшәүче язучылар һәм шагыйрьләрне барлау, иҗатларын өйрәнү һәм укучыларны аларның иҗаты белән таныштыру;
- укучыларда милләткә һәм Ватанга хөрмәт тәрбияләү, милли үзаң формалаштыру, татар халкы тарихын өйрәнү, рухи байлыкларны саклау һәм үстерү, телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт тәрбияләү;
- хәзерге укучыларның гомуми һәм коммуникатив культурасын, социаль адаптациясен һәм гражданлык активлыгын үстерү, фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш һәм кызыксыну тәрбияләү;
- тикшеренү коллективлары белән иҗади мөнәсәбәтләр формалаштыру, бергәләп тере аралашуны оештыру;
- сәләтле укучыларны һәм укытучыларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру;
- укытучыларның алдынгы тәҗрибәсен барлау, эзләнү эшенә тартып, аларны фәнни эшләргә җәлеп итү;
- республиканың төп һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназия, укытучыларының һөнәри үсеш юлларын билгеләү, педагогик тәҗрибәне тарату.

III. Конференцияне оештыручылар

3.1. Конференцияне оештыручылар:

- Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Татарстан Язучылары берлеге, Язучыларның Чаллы бүлеге;

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет учреждениесе “Мәгълүмати-методик үзәк»;
- Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”.

IV. Конференциядә катнашучылар

4.1. Конференциядә гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучылары, урта гомуми белем бирү оешмаларының укытучылары катнаша ала.

V.Конференциянең эш юнәлешләре

5.1.1. Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатына багышланган IV төбәкара фәнни-гамәли конференциянең эш юнәлешләре:

Укучылар өчен.

1. Нәфис сүз. Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатыннан шигырь, яки әдәби әсәрдән өзек (1 – 6 сыйныф укучылары өчен).

2. Фәнни-гамәли эш. Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатында шәһәр тарихы, КамАЗ заводы һәм сугыш темасы бирелеше (5 – 11 сыйныф укучылары өчен).

Укытучылар өчен.

Түгәрәк өстәл: фәнни эшләр, мастер-класс, чыгышлар. Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләренең иҗатын милли региональ компонент буларак татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә куллану.

VI. Фәнни-гамәли хезмәтләргә таләпләр

6.1.1.Фәнни-гамәли эшләрне һәм укучыларның чыгышын бәяләү критерийлары:
- сайланган теманың актуальлеге;
- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, оригинальлеге; эштә кулланылган материалларның сыйфаты;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- чыгыш композициясе, материалны ачу тирәнлеге, дәлилләр;
- эшне күрсәтмәлелек һәм мавыктыргыч итеп күрсәтү;
- куелган проблема буенча әдәбият, чыганакларны куллану, эшләрдә сылтамалар дөрес куелу.

**Искәрмә: 1. Фәнни эшләрдә бер автор һәм укучыларның фәнни эшләрендә җитәкче бер генә була ала.**

6.2.Фәнни-гамәли хезмәтләр, чыгышлар бары тик татар телендә генә кабул ителә.

6.3. Хезмәтнең язылу тәртибе.

Текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш. Тикшеренү эшенең кушымтасы рәсемнәр, схемалар һәм карталар, фотолар, кушымта күләме 5 бит булырга мөмкин. Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman-14, интервал 1,5, уңнан-1,5; сулдан-2,5 астан-2; өстән-1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла һәм кире кайтарылмый.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, район, катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема, эшнең юнәлеше һәм җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

**Республикакүләм башка конкурсларда катнашып призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.**

6.3. **Чыгыш регламенты** һәм бәяләү критерийлары.

Жюри әгъзалары укучыларның һәм укытучыларның тикшеренү эшләрен түбәндәге критерийлар буенча бәялиләр:

- проблеманы ачу тирәнлеге, бөтенлек, махсус техника һәм техниканы куллану;
- дөрес логикага буйсынган һәм исбатлау өлеше булган көчле аргументлар һәм нәтиҗәләр күрсәтү; фәнни эш; эш максатларын дөрес билгеләү;
- чыгышның композицион тәгәллеге, үз фикереңне раслый белү, теманы ачу дәрәҗәсе;
- тәкъдим ителгән эшнең хәзерге заман шартларына туры килүе, күрсәтмә материалның булуы;
- аралашу һәм сөйләм культурасы;
- жюри сорауларына җавапларның сыйфаты;
- хезмәтләрне күрсәтмә материаллар, презентацияләр белән баету.

Чыгышларның озынлыгы 5-7 минут. Чыгыш вакытында укучы төп уйларны һәм нәтиҗәләрне кыскача һәм ачык итеп күрсәтергә тиеш. Компьютер презентациясе хуплана. Эшләр электрон һәм кәгазь вариантта кабул ителә (икенче турга узучылар кәгазь вариантын алып киләләр).

## VII. Конференцияне үткәрү тәртибе

7.1. Оештыру комитеты конференциядә катнашу өчен гаризаларны сайлап алу хокукын үзендә калдыра.

7.2. Конференция Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”ндә үткәрелә.

7.3. Конференция 2 этапта үткәрелә:

I этап – сайлап алу этабы. Фәнни-гамәли эшләрне, тезисларны 2026 нче елның 15 февраленә кадәр **dgauhar75@mail.ru** электрон адресына «Конференция», авторның фамилиясен күрсәтеп, **архивлаштырмыйча** җибәрергә. Фәнни-гамәли эштә, тезиста катнашучының исемен күрсәтергә. Күрсәтелгән вакыт узгач эшләр кабул ителми.

II этапка узучылар исемлеге 2026 нче елның 16 февралендә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”нең официаль сайтына эленә.

https://edu.tatar.ru/n_chelny/sch21chelny

II этап – йомгаклау этабы. Икенче турга узучылар 2026 нче елның 18 февралендә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”нә чакырыла. Конференциягә теркәлү – 11.30 сәгатьтә; башлану вакыты - 12.00.

Эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

Элемтәгә керү өчен кәрәзле телефон һәм макс: 89872389640 (татар теле һәм әдәбияты укытучысы Демухаметова Гәүһәр Фаяз кызы)

7.4. Конференциядә катнашу өчен, гариза-заявканы түбәндәге сылтама буенча тутырырга. https://forms.gle/gDNkEG6Tsu4fRsnF9

7.5. Конференциядә катнашу өчен 200 сум күләмендә (һәр эш өчен) оештыру взносы түләргә кирәк. Оештыру взносы дипломнар, сертификатлар, оештыру эшләре өчен тотыла: *кушымта №1*

## VIII. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Республикакүләм фәнни-тикшеренү конференциядә катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясенең карары протоколлаштырыла, үзгәрешләр кертелми.

Фәнни-гамәли конференциядә җиңүчеләргә дипломнар, сертификатлар, рәхмәт хатлары тапшырыла, дистанцион формада үткәрелсә һәм икенче турга узмаучыларга 24 нче февральдән соң гаризада күрсәтелгән электрон адреска җибәрелә.

*Кушымта №1*

## РЕКВИЗИТЫ

| | |
|---|---|
| Полное наименование организации | муниципальное автономное общеобразовательное учреждение города Набережные Челны «Средняя общеобразовательная школа № 21» |
| Краткое наименование организации | МАОУ «СОШ № 21» |
| Юридический адрес, фактический адрес | РТ, г. Набережные Челны, ул. Железнодорожников д. 65 |
| Почтовый адрес | 423806 РТ, г. Набережные Челны, ул. Железнодорожников д. 65 |
| ИНН/КПП | 1650083359/165001001 |
| ОГРН | 1031616010030 |
| ОКАТО | 92430000000 |
| ОКТМО | 92730000 |
| ОКПО | 56355732 |
| ОКОНХ | 1392310 |
| ОКВЭД | 85.14 |
| ОКОПФ | 7.54.01 |
| ОКФС | 14 |
| ОКДП | 2548756 |
| ОКАТО | 92430000000 |
| ОКПО | 56355732 |
| Расчетный счет | 03234643927300001100 |
| л/с | ЛАВ30800070-СОШ21, ЛАЗ30800070-СОШ21 |
| л/с | ЛАГ30800069-СОШ21 |
| л/с | ЛАО30800729-СОШ21 ЛР308000129-СОШ21 |
| Наименование банка | ОКЦ № 6 ВВГУ Банка России |
| Корреспондентский счет | 40102810445370000079 |
| БИК | 019205400 |
| Телефон /факс | 8(8552)46-66-31 |
| ГМУ | 0711000000179 |